СОВЕТ УРУСОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРЫС АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423706,Республика Татарстан,
Мензелинский район, д. Урусово, ул. Дружбы, 42

423706, Татарстан Республикасы,
Минзәлә районы, Урыс авылы, Дружбы урамы,42

телефон: (85555)2-79-86 E-mailUrus.Mnz@tatar.ru

ОКПО 4308290 ОГРН 1021605552880 ИНН/КПП 1628002805/162801001

№1 от15.04.2019г.

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл жирлеге территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган территорияләрнең кайбер объектлары һәм оешмалары янәшәсендәге чикләрне билгеләү турында

22.11.95 елдагы “Этил спиртын, алкоголь һәм составында спирт булган продукцияне җитештерүгә һәм аның әйләнешен контрольдә тотуга һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләүгә дәүләт җайга салуы турында”гы №171-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 27.12.2012 елдагы “Алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган гражданнарның күпләп җыела торган урыннарын һәм югары куркыныч чыганаклары урнашкан урыннарны Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләү, шулай ук, алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган территорияләрнең объектлары һәм кайбер оешмалары янәшәсендәге чикләрне җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү турында”гы № 1425 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл жирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган янәшәдәге территорияләр чикләренә кадәр балалар, белем бирү, медицина оешмалары, спорт объектлары һәм гражданнар күпләп җыела торган башка урыннардан (алга таба – оешма) ераклыкны исәпләү һәм янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү түбәндәгечә башкарыла:
1.1. Оешманың территориясе булганда, ераклык җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату башкарылган стационар сәүдә объектына (алга таба – сәүдә объекты) килүчеләргә керү

юлына кадәр территориягә керүчеләр өчен керү юлларыннан кыска ераклык буенча үлчәнә.

1.2. Оешманың территориягә берничә керү юлы һәм (яисә) сәүдә объектының берничә керү юлы булганда, ераклык сәүдә объектына килүчеләр өчен һәр керү юлына кадәр территориягә керүчеләр өчен һәр керү юлыннан кыска юл буенча үлчәнә.

Оешманың территориясе булмаган очракта, ераклык бинага (корылмага) килүчеләр өчен керү юлыннан сәүдә объектына килүчеләр өчен оешма урнашкан керү юлына кадәр үлчәнә. Оешма урнашкан сәүдә объекты яисә бинаның (корылма) килүчеләр өчен беринчә керү юлы булганда, ераклык һәр керү юлыннан үлчәнә.

1.3. Сәүдә объектлары һәм оешмалар бер бинада урнашкан очракта, ераклык сәүдә объекты урнашкан бина өлешенә килүчеләр өчен керү юлыннан башлап, оешма урнашкан бина өлешенә килүчеләр өчен керү юлына кадәр иң кыска ераклык буенча үлчәнә.

2. Алкоголь продукциясен ваклап сату тыелган сәүдә объекты янәшәсендәге территорияләрнең чикләренә кадәр оешмалардан ераклыкның минималь билгесен билгеләргә:

2.1. Халык күп җыела торган һәм югары куркыныч чыганаклары булган урыннар өчен – 100 метр;

2.2. Балалар, белем бирү оешмалары, спорт объектлары өчен - 100 метр;

2.3. Стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче, дәвалау-профилактика медицина оешмалары, аерым төрдәге медицина оешмалары өчен – 100 метр;

2.4. Стационар булмаган шартларда медицина ярдәме күрсәтүче дәвалау-профилактика медицина оешмалары, кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча медицина оешмалары өчен – 100 метр.

3. Гамәлдәге карар рәсми төстә басылырга тиеш.

4. Гамәлдәге карарны контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет рәисе Ф.М. Маулин